РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
АЛАБЕРДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАБИРДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 58-0-37, факс 58-0-37

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**17.12. 2024** **№ 3**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЛАБИРДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНА КЕРГӘН ГРАЖДАННАР МӨРӘҖӘГАТЬЛӘРЕНӘ АНАЛИЗ ЯСАУ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Алабирде авыл җирлеге Советына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.И. Хәкимов**